| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.08.2021 Әгерҗе шәһәре № 11-12

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-3 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым бурычын каплау эшен оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 16-54/16211 номерлы, «МНПАга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы, 2021 елның 19 гыйнварындагы 11/13-09/140 номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм процедурасын регламентлаштыра торган муниципаль норматив хокукый актлар исемлеген исәпкә алып, «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында норманы регламентлый торган» Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2021 елның 26 гыйнварындагы 01-05-399 номерлы «Салым бурычларын түләүне оештыру турында» запросларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-3 номерлы карарына кушымтада бирелгән үзгәрешне расларга.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының
«17» 08 2021 ел, № 11-12
карары белән расланган

**«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2021 елның 29 июнендәге 10-3 номерлы карарына кертелүче ҮЗГӘРЕШ**

1.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1) 5 бүлекнең 5.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.9.7 пунктчасын өстәргә:

«5.9.7. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».